ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

« 9 » июль 2019 ел. № 506

**Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендә чыккан «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм аз халыклы авылларга товарлар китерүгә бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында "гы 887 нче номерлы карарын үтәү максатыннан Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

- Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен 1 нче кушымта буенча;

- субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составын 2 нче кушымта буенча.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитеты җитәкчесе И.А. Галимуллин

Арча районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 нчы елның 9 шыгендә чыккан 506 нчы номерлы карарына 1 нче кушымта

**Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнанераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү**
**Тәртибе**

1.1 .Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендә чыккан «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан аз халыклы авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 887 нче номерлы карары нигезендә эшләнде.

1.2. Субсидия алу хокукына түбәндәге критерийларга җавап бирүче оешмалар ия:

- Арча муниципаль районы территориясендә теркәлгән юридик зат;
- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районыүзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык аз яши торган авылларга беренче чиратта кирәк булган товарларны китерүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник чаралары булганнар;
-2.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы пакетын тапшыручылар.

1.3. Субсидия беренче чиратта кирәк булган товарларны Арча муниципаль районының ерак һәм халык аз яшәгән авылларга китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында бирелә.

1.4 Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау буенча субсидияләр

күләме бу максатларга Арча муниципаль районы бюджетында каралган акчалардан күбрәк була алмый.

1.5. Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарны кайтару Арча муниципаль башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия алучы субсидия алу һәм Килешү төзү өчен (алга таба Килешү) Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлегенә түбәндәге документлар тапшыра:

а) Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнар турында мәглуматны үз эченә алган хисап күрсәтелгән һәм әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасында билгеләнгән тәртиптә язылган гариза (гаризалар журналында теркәлә)

б) гамәлгә куючы документ күчермәләре;

в) оешма җитәкчесенең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе;

г) юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язылу турында таныклык күчермәсе;

д) Россия Федерациясе территориясендә урнашкан урын буенча салым органында юридик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

е) ике елдан артык эшчәнлек алып барган очракта салым органы тамгасы сугылган соңгы ике еллык бухгалтерлык хисапларының күчермәсе;

ж) субсидия күләме исәпләнгән хисап документы;

з) Арча муниципаль районы үзәгеннән -Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү буенча тотылган чыгымнарны раслаучы документлар;

и) әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында билгеләнгән критерийларны раслый торган документлар.

Түләү реквизитлары күрсәтелгән бюджетара трансфертлар бирү турында гариза, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы арасында килешү (алга таба - Министрлык), Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык аз яшәгән авылларга товар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль

берәмлекләргә бюджетара трансфертлар бирү турында белешмә Министрлык тарафыннан расланды.

Башка бюджетара трансфертларны алучыларга бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык аз яшәгән авылларга товарлар китерүгә бәйле куллланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»гы 887 номерлы карары белән расланган.

2.1.1. Субсидия алучыларга килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә туры килергә тиешле таләпләр:

- субсидия алучыларның салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнары, җыемнары иминият взнослары, пенялар, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмаска тиеш;

- субсидия алучыларның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычлары, субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты каршында түләнмәгән бүтән бурычлары булмаска тиеш;

- субсидия алучы юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидия алучы шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

- субсидия алучылар чит ил юридик затлары, шулай ук устав (склад) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше һәм (яки) финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган(50процентттан артык түгел), аларның теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган дәүләт яисә территория исемлегенә кертелгән Россия юридик затлары булырга тиеш түгел;

- субсидия алучылар әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан акча алырга тиеш түгел.

2.2. Гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик

затларга субсидия бирү турында беркетмә нигезендә карар кабул итүче комиссияне (алга таба - Комиссия) җыя.

Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге, комиссия карары кабул ителгәннән соң 1 эш көне эчендә, субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә. Субсидия бирү турында Карар Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге тарафыннан башкарма комитетның исәп-хисап бүлегенә җибәрелә.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- субсидия алучы тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тулы күләмдә тапшырмау (бирмәү) ;

- субсидия алучы биргән документларның әлеге Тәртипнең 2.1.1 пунктындагы таләпләргә туры килмәве;

- субсидия алучы тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы.

2.3. Субсидия алучы белән Арча муниципаль районы башкарма комитеты арасында әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә субсидия бирү өчен төзелгән килешү (алга таба - килешү) субсидия бирү өчен нигез булып тора.

2.4. Субсидия бирү турындагы килешүдә ике якның да хокуклары һәм бурычлары, акча күчерү шартлары һәм тәртибе, хисап бирү тәртибе, килешүнең гамәлдә булу срогы, аның үтәлешен контрольдә тоту, якларның җаваплылыгы, килешүне өзү тәртибе, агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгын кире кайтару тәртибе, субсидия алучыга Арча муниципаль районы Башкарма комитеты һәм «Арча муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесенең субсидия алучыга субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп тору тәртибе турында язылган булырга тиеш.

2.5. Субсидияләрне Арча муниципаль районы башкарма комитетының исәп һәм хисап бүлеге банкта ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

2.6. Субсидия акчалары максатчан характерда тотылырга тиеш һәм башка максатларда кулланыла алмый.

2.7. Арча муниципаль районы башкарма комитеты һәм «Арча муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе аларны алучыларга субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен мәҗбүри рәвештә тикшерә.

## III. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

3.1. Субсидия алучы аны бирү шартларын бозган очракта, субсидияләрне күчерү хокук бозуларны бетергәнчегә кадәр туктатыла.

3.2. Арча муниципаль районы башкарма комитеты яисә бюджет акчаларының максатчан кулланылуын, субсидияне максатсыз файдалану фактларын контрольдә тотарга вәкаләтле органнары тарафыннан субсидияне максатсыз файдалану очраклары ачыкланганда, субсидия алучы артык алынган акчаны Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтара.

3.3. Әлеге акчаларны кире кайтарудан баш тарткан очракта, аларны түләтү суд тәртибендә гамәлгә ашырыла.

3.4. Субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда хисап елында файдаланылмаган субсидия калдыгы Арча муниципаль районы бюджетына алдагы елның 1 февраленә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә 1нче кушымта

Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә
______________________________________
Адресым:_____________________________
______________________________________
«___ »_________________ 20___ел

**Субсидия бирүгә (күчерүгә) гариза**

Арча муниципаль районының үзәгеннән –Арча шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык аз яшәгән авылларга беренче чиратта кирәк булган товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен кире кайтаруны каплау өчен ____________________сум субсидия бирүегезне сорыйм.

Субсидия күләмен исәпләү:

_________________________________________________________________

Кушымта итеп бирелә торган документлар:

1. Арча муниципаль районының үзәгеннән –Арча шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык аз яшәгән авылларга беренче чиратта кирәк булган товарларны китерү белән бәйле чыгымнарны дәлилләүче документлар.

Җитәкче
Баш хисапчы
М. П.

Арча муниципаль районы үзәгеннән-Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә 2 нче кушымта

форма

## Арча муниципаль районының үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан һәм халык аз яшәгән авылларга беренче чиратта кирәк булган товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында субсидияләр бирү турында Килешү

Арча шәһәре «___» ____________20___ел

Алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы Нигезләмә нигезендә эш итүче Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе ________________________________________________________ һәм алга таба "Субсидия алучы" дип аталучы__________________________________________ нигезендә эш итүче ________________________________________, бергә "Яклар" дип аталучылар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендә чыккан «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан аз халыклы авылларга беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 887 нче номерлы карары нигезендә әлеге Килешүне төзеделәр.

1. Килешү предметы

1.1. Килешүнең предметы- Арча муниципаль районы үзәгеннән –Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга башкарма комитет тарафыннан субсидия алучыга Арча муниципаль районы бюджетыннан бушлай һәм кире кайтарылмый торган нигездә субсидияләр бирү.

1.2. Субсидия аны алучыга агымдагы финанс елына Арча муниципаль районы бюджетының ирекле бюджет язмасында бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле кодлары буенча башкарма комитетта каралган бюджет ассигнованиеләре һәм йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Арча муниципаль районы үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатында бирелә.

Субсидиянең суммасы_____________(_____________ ) сум.

1.3. "Субсидия алучы» үз өстенә түбәндәге йөкләмәләр ала:

1.3.1. Субсидияне Арча муниципаль районы үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланырга.

1.3.2. Арча муниципаль районы үзәгеннән –Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарны аерым исәпкә алып барырга.

1.3.3 Арча муниципаль районы үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарны каплауга тотылган субсидияләр күләмен исәпләп чыгарырга һәм чыгымнарны һәрбер статья буенча нигезләп, исәп-хисапны башкарма комитетка тапшырырга.

1.4. Субсидияләрнең максатчан кулланылышы булып субсидия алучының әлеге Килешүнең 1.3 пунктында санап үтелгән йөкләмәләрне үтәве тора.

2. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1.Субсидия Арча муниципаль районы үзәгеннән –Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау максатында бушлай һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.

2.2. Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр күчерү “Субсидия алучының” Россия Федерациясе Үзәк банкында яисә кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына “Башкарма комитет”счетыннан билгеләнгән тәртиптә бер тапкыр Арча муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү мәсьәләсен карау буенча эшче төркем тарафыннан карар кабул ителгәннән соң ун көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

2.3. “Башкарма комитет” 1.3.3 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң 2 календарь көн эчендә субсидия күләмен исәпләүне тикшерә һәм актын төзи.

2.4. Арча муниципаль районы бюджетыннан акча күчерү өчен нигез булып “Башкарма комитетның”Арча муниципаль районы үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр күләмен исәпләү акты тора.

2.5. “Субсидия алучының” әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләреннән тыш булган чыгымнары Арча муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына түләнергә тиеш түгел.

2.6. “Башкарма комитет” һәм “Арча муниципаль районы Контроль-хисап палатасы” муниципаль казна учреждениесе “Субсидия алучы”га субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри рәвештә тикшерә.

2.7. “Субсидия алучы” әлеге килешү белән”Башкарма комитет” һәм «Арча муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерү өчен ризалыгын белдерә.

3. Якларның хокуклары һәм бурычлары;

«Башкарма комитет»:

3.1. Субсидия суммасын әлеге килешүнең 2 статьясы шартлары нигезендә «Субсидия алучының» исәп-хисап счетына күчерә.

3.2. Килешү буенча «Субсидия алучы»ның йөкләмәләрен үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча «Субсидия алучыга» консультация бирә.

3.3.” Субсидия алучы” тарафыннан субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерергә тиеш.

3.4. Түбәндәге очракларда субсидияне тулысынча яисә өлешчә бирергә хокуклы:

- «Субсидия алучыга» карата аның зшчәглеген бетерү, үзгәртеп кору, банкротлык процедуралары башкарыла икән, шулай ук аның эшчәнлеге гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә туктатылган булса;

- “Субсидия алучы “тарафыннан әлеге тәртипнең 1.3 пунктында билгеләнгән йөкләмәләрнең үтәлмәве. Арча муниципаль районы үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүнең билгеләнгән тәртибе таләпләрен системалы рәвештә бозу.

"Субсидия алучы» үз өстенә түбәндәге йөкләмәләр ала:

3.5. Арча муниципаль районы үзәгеннән–Арча шәһәреннән 11 чакрымнан ерактарак урнашкан һәм халык саны аз булган авылларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бирелгән субсидияләрне кулланырга.

3.6. «Башкарма комитет» таләбе буенча килешү предметына кагылышлы барлык кирәкле мәгълүматны һәм документларны тапшырырга.

3.7.Килешү буенча үз бурычларын һәм хокукларын башка кешегә күчерергә тиеш түгел.

3.8. Вәкаләтле орган тарафыннан "Субсидия алучы"га карата эшчәнлеген үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул ителгәндә, 5 (биш) календарь көненнән дә соңга калмыйча бу хакта “Башкарма комитет " ка язма рәвештә хәбәр итәргә.

3.9. Килешүнең башка шартларын тиешенчә үтәргә.

3.10. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына бирү өчен, әлеге Килешүгә кушымта нигезендә, агымдагы елның 20 декабренә кадәр субсидияне максатчан файдалану турында хисап бирергә.

4. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

4.1. «Субсидия алучы» дөрес булмаган мәгълүмат биреп, субсидияләр бирү шартларын бозып яки аларны максатчан кулланмыйча нигезсез субсидия алган очракта, “Башкарма комитет”әлеге фактлар ачыклану көненнән башлап10 календарь көн эчендә «Субсидия алучыга» Арча муниципаль районы бюджетына бирелгән субсидияне кире кайтару турында таләп куя.

4.2. Субсидияләр бирүне туктату һәм (яки) субсидияләрне кире кайтару турындагы карарны «Башкарма комитет " кабул итә.

4.3. Субсидияләрне кире кайтару “Субсидия алучы” тарафыннан «Башкарма комитет»- ның Арча муниципаль районы бюджетына язмача таләпләрен алган көннән соң,”Башкарма комитетның” Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык Департаментының территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына 30 календарь көн эчендә бәхәссез рәвештә башкарыла.

4.4. «Субсидия алучы " тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидия субсидия бирү турындагы килешүдә каралган очракларда «Башкарма комитетның “ Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыгы” Департаментының территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерү юлы белән хисап елыннан соңгы елның 1 нче гыйнварына кадәр кире кайтарылырга тиеш.

4.5. Субсидияләрне ирекле кире кайтарудан баш тартканда, акча Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә түләтелә.

5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирәләр.

6. Якларның җаваплылыгын юкка чыгара торган шартлар (форс-мажор хәлләр)

6.1. Яклар килешү буенча үз бурычларын үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен бу килешү төзегәннән соң барлыкка килгән үти алмаслык шартлар, атап әйткәндә: табигый бәла-казалар, сугыш башлану яки гадәттән тыш хәлләр кертү, террорлык актлары, массакүләм тәртипсезлекләр, дәүләт органнарының эшчәнлегендә һәм Россия Федерациясе законнарында үзгәрешләр килеп чыкканда җаваплылыктан азат ителәләр. Мондый шартлар туу факты һәм аларның дәвамлылыгы компетентлы орган тарафыннан расланган булырга тиеш.

6.2. Яклар әлеге шартлар туган очракта бер-берсенә ундүрт көн эчендә форс-мажор хәле турында язмача хәбәр итәргә тиеш. Мөрәҗәгатьтә шартларның характеры турында мәгълүматлар, шулай ук әлеге шартлар булуны раслаучы һәм килешү буенча якларның үз йөкләмәләрен үтәүгә йогынтысын бәяләүче рәсми документлар булырга тиеш.

6.3. Әгәр дә бер як 6.2 пунктта каралган хәбәр җибәрмәсә яки вакытында җибәрмәсә, каршы якка салынган зыянны үз хисабына капларга тиеш.

6.4. Килешүнең 6.1 пунктында күрсәтелгән хәлләр килеп чыккан очракларда яклар тарафыннан килешү буенча йөкләмәләрне үтәү срогы әлеге шартлар гамәлдә булган вакыт аралыгына күчерелә.

6.5. 6.1 пунктында саналган хәлләр 2 айдан артык дәвам итсә, Яклар Килешүне үтәүнең башка алымнарын билгеләү өчен сөйләшүләр үткәрә.

7. Килешү шартларын үзгәртү.

Яклар килешүләргә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә хокуклы. Мондый үзгәрешләр һәм өстәмәләр аерым өстәмә килешүләр рәвешендә рәсмиләштерелә һәм аның аерылгысыз өлеше була.

8. Бәхәсләр туган очракта аны чишү юллары

8.1. Яклар арасында килеп чыгарга мөмкин булган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсле мәсьәләләрне сөйләшүләр юлы белән җайга салу мөмкин булмаганда, бәхәсләр Арбитраж судында хәл ителә.

9. Килешүнең гамәлдә булу срогы

Килешү яклар тарафыннан кул куелган вакыттан үз көченә керә һәм башканы билгели торган очраклар булмаганда _____________елның _______________кадәр гамәлдә булачак.

10. Өстәмә шартлар

10.1. Килешүдә каралмаган очракларда яклар Россия Федерациясе законнарына таянып эш итәләр.

10.2. Яклар тарафыннан килешү буенча бер-берсенә җибәрелә торган теләсә- кайсы хәбәр язмача булырга тиеш. Килешүнең 11 пунктында күрсәтелгән адресатка юллама яки заказлы хат белән һәм вәкаләтле затның имзасы белән җибәрелсә, мондый белдерү яисә хәбәр тиешенчә юлланган дип санала.

10.3. Юридик адрес, урнашу урыны, статусы яки түләү реквизитлары үзгәргән очракта яклар өч көн эчендә бу хакта бер-берсенә хәбәр итәргә тиеш.

10.4. Килешү бер үк юридик көчкә ия 2 (ике) нөсхәдә төзелгән, аларның берсе «Субсидия алучыга» тапшырыла, ә икенчесе «Башкарма комитет»та саклана.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 9 июлендә чыккан 506 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия СОСТАВЫ**

Комиссия рәисе Шәрәфетдинов З. З.-Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары

Комиссия секретаре Нәбиуллин И. М. – Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге җитәкчесе

Комиссия әгъзалары:

Галимуллина Г. Х.-Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге баш белгече

Шәрифуллин И. Р. –Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге баш белгече